ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
(V чакырылыш)

**V чакырылышның чираттан тыш утырыш**
**КАРАРЫ**

**№ 6** **Әбсәләм ав.** **25 «март» 2026 ел**

Абсәләм авыл җирлеге Советының 2024 елның 9 декабрендәге 26 санлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлегендә бюджет процессы турында"гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2025 елның 20 мартындагы «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2025 елның 28 ноябрендәге «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 432-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы К А Р А Р И Т Т Е:

1. Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2024 елның 09 декабрендәге 26 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлегендә бюджет процессы турында»гы нигезләмәгә (2025 елның 19 августындагы 17 санлы, 2025 елның 26 декабрендәге 16 санлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 12 маддәнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 маддәсе нигезендә билгеләнә торган тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;».

2. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгару һәм массакүләм коммуникацияләр чаралары сыйфатында теркәлү турында таныклык (Роскомнадзор) һәм “Рәсми Татарстан” дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В.Кубашева